КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 ноябрь г.Казань № 932

Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Президентын, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, Татарстан Республикасы Президентын, җирле үзидарә органнарының вәкаләтле органнары депутатларын сайлауларны (алга таба – сайлаулар) әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләүдә сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү һәм аларны үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча бу карарга теркәлгән кушымтада бирелгән составта эшче төркем төзергә.

2. Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлегенә – Татарстан Республикасы Милли банкына (Милли банкның учреждениеләре булмаган очракта – «Россия Саклык банкы» гавами акционерлар җәмгыятенең «Татарстан Банкы» 8610 нчы бүлегенә) – сайлауларны әзерләү һәм үткәрү өчен сайлау комиссияләренә бүлеп бирелә торган тиешле бюджет акчасы белән операцияләр башкару өчен сайлау комиссияләре исәпләрен, ә «Россия Саклык банкы» гавами акционерлар җәмгыятенең «Татарстан Банкы» 8610 нчы бүлегенә сайлау берләшмәләре, кандидатларның махсус сайлау исәпләрен ачуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсенә түбәндәгеләрне кертергә, шулай ук Татарстан Республикасының

Хәрби комиссариатына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, судларга – кертүне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасы турындагы нигезләмә хакында» 1997 ел, 6 ноябрь, 134/973-II нче карары һәм Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасының Татарстан Республикасында функцияләвен тәэмин итү чаралары турында» 2006 ел, 1 март, ПУ-78 нче Указы белән күздә тотылган мәгълүматларны муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләренә әлеге хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда.

4. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә, сайлау кампанияләре барышында билгеләнгән компетенция чикләрендә түбәндәгеләрне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

а) сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чорында җәмәгать куркынычсызлыгын һәм җәмәгать тәртибен саклауны, шул исәптән сайлау комиссияләре урыннарын, тавыш бирү урыннарын һәм сайлау комиссияләре сораулары буенча сайлау документларын алып барганда аларны түләүсез нигездә саклауны;

б) хокукка каршы агитация, шул исәптән «Экстремизм эшчәнлегенә каршы тору турында» Федераль законның 1 статьясы нигезендә экстремизм эшчәнлеген туктату, ялган һәм законсыз сайлау алды агитация материалларын әзерләүне булдырмау һәм аларны тартып алу, әлеге материалларны әзерләүчеләрне һәм таратучыларны, аларга түләү чыганакларын ачыклау, хокукка каршы башка агитация эшчәнлегендә катнашучыларны билгеләү буенча кичектергесез чаралар күрүне, шулай ук тиешле сайлау комиссияләренә ачыкланган фактлар һәм кабул ителгән чаралар турында үз вакытында хәбәр итүне, материалларны судка үз вакытында җибәрүне;

в) Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, башка сайлау комиссияләре сораулары буенча имза куелган битләрдәге кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен тәкъдим итүгә теләктәшлек белдерүдә үз имзаларын куйган сайлаучылар турындагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерүне үткәрүне.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә сайлау

комиссияләре сораулар буенча тикшерүләрне үз компетенцияләре чикләрендә үткәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына сайлау кампанияләре барышында сайлау комиссияләре урыннарында һәм тавыш бирү урыннарында янгын куркынычсызлыгын саклауны тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Татарстан Республикасының Хәрби комиссариатына сайлау кампанияләре барышында сайлау комиссияләренә сак астында тоту урыннарында, төзәтү үзәкләрендә булган җинаять кылуда шикләнелүче һәм гаепләнүче гражданнар, административ арестка алынган затлар өчен махсус учреждениеләрдә булган гражданнар, шулай ук йорт арестында булган затлар тавыш биргәндә Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларын тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль законның 47 статьясындагы 7 нче пунктта күрсәтелгән исемлекләрне формалаштыру өчен кирәкле мәгълүматларны, теле- һәм (яки) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар турындагы; сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә гамәлгә куючылары (гамәлгә куюдашчылары) яки редакцияләрен гамәлгә куючылары (гамәлгә куюдашчылары) Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар булып торган һәм (яки) сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә кадәр 1 ел алдан Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан аларның эшчәнлегенә бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән (мондый ассигнованиеләрнең төре һәм күләме турындагы белешмәләрне күрсәтеп) һәм (яки) устав (җыелма) капиталында сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган көнгә) Татарстан Республикасы өлеше (кертеме) булган даими басма матбугатлары турында мәгълүматларны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә үз вакытында тапшыруны гамәлгә ашырырга.

9. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына сайлау кампанияләре барышында теле- һәм (яки) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы төбәк дәүләт оешмалары һәм төбәк дәүләт матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан сайлау комиссияләренә, сайлаулар дәрәҗәсенә туры китереп, сайлаучыларга мәгълүмат бирү өчен түләүсез эфир вакытын һәм сайлау комиссияләре карарларын бастырып чыгару һәм башка мәгълүматны бастырып чыгару өчен басма мәйдан бирүне тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

10. Россия Федерациясенең Пенсия фондына инвалидлык төркемнәре һәм организм функцияләренең ныклы җитешсезлекләре төрләре буенча тиешле территориядә инвалид булган сайлаучылар саны турындагы мәгълүматны «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 20 статьясындагы 16.1 нче пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта кертүне тәкъдим итәргә.

11. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясенең инвалид булган гражданнарының сайлау хокукларын аларда организм функцияләренең ныклы җитешсезлекләре төрләрен исәпкә алып тәэмин итү эшендә сайлау комиссияләренә, шулай ук әлеге гражданнарга Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссияләре арасында төзелә торган килешү нигезендә кирәкле ярдәм күрсәтүдә булышлык күрсәтергә.

12. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына сайлау кампанияләре барышында барлык дәрәҗәләрдәге сайлау комиссияләре мәнфәгатьләрендә гомуми файдаланудагы элемтә челтәренең элемтә хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән сегменты өзлексез эшләүне тәэмин итү буенча, шул исәптән «Сайлаулар» Россия Федерациясе автоматлаштырылган дәүләт системасы эшләве өчен чаралар күрергә.

13. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә, электрон тавыш бирү комплекслары, сайлау бюллетеньнәрен эшкәртү комплекслары файдаланылачак, участок сайлау комиссияләренең машина укый ала торган кодлы беркетмәләрен әзерләү һәм участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре мәгълүматларын, машина укый ала торган кодны файдаланып, «Сайлаулар» Россия Федерациясе дәүләт автоматлаштырылган системасына кертү технологиясе кулланылачак «Сайлаулар» Россия Федерациясе дәүләт автоматлаштырылган системасын автоматлаштыру чаралары комплексларын, территориаль сайлау комиссияләре сайлаучыларының гаризаларын кабул итү буенча автоматлаштырылган эш урыннарын, сайлаучыларның тавыш бирү урыннарын урнаштыру өчен бирелә торган урыннарны, шулай ук Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе урнашкан бинаны резерв автоном энергия белән тәэмин итү мөмкинлеген карарга.

14. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрдә булышлык күрсәтергә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына – булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә:

сайлау кампанияләре чорында сайлаучылар вакытлыча булу урыннарында (хастаханәләр, шифаханәләр һәм ял йортлары, вокзаллар, аэропортлар, шикләнүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту урыннары һәм башка вакытлыча булу урыннары) сайлау участокларын сайлау законнары белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда оештыруда, шулай ук тиешле участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрен, сайлау бюллетеньнәрен – югары сайлау комиссияләренә, башка сайлау документларын әлеге сайлау участокларында формалаштырылган участок сайлау комиссияләренә алып баруда.

15. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Татарстан Республикасының Хәрби комиссариатына сайлау кампанияләре чорында тиешле органнарда һәм хәрби частьләрдә хезмәт итүче гражданнарның, шулай ук хәрби часть урнашу территориясендә (буйсынуы буенча) яшәүче гражданнарның сайлау хокукларын тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

16. Сайлау кампанияләре чорында Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итү мөмкинлеге турында тәкъдимнәр кертергә:

сайлау комиссияләренә, шулай ук сайлау берләшмәләренә һәм теркәлгән кандидатларга закон белән билгеләнгән тәртиптә тиешенчә эфир вакыты һәм басма мәйдан биргәндә, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль закон таләпләрен бозган теле- һәм (яки) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларга, шулай ук вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә, челтәрле басмалар редакцияләренә карата үз вакытында тиешле чаралар күрүне (тиешле административ хокук бозулар турындагы материалларны судка җибәрүне дә кертеп);

Татарстан Республикасы территориясендә эшләнә һәм (яки) таратыла торган басма, аудио- һәм аудиовизуаль массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясе эчтәлеген аның Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының сайлаулар турындагы законнары таләпләренә туры килү-килмәвен ачыклау максатларыннан чыгып анализлауны;

сайлау комиссияләренә аларның сораулары буенча массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү һәм (яки) тапшыруларга лицензияләр булу-булмау турындагы мәгълүматларны, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлегенә кагылышлы башка материалларны оператив кертүне.

17. Сайлау кампанияләре чорында Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына түбәндәгеләрне командировкага җибәрергә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия

Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсенә, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – командировакага җибәрүне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, башка сайлау комиссияләре соравы буенча тиешле сайлау комиссияләре каршындагы тикшерү-ревизия хезмәте составында эшләү өчен белгечләрне.

Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлегенә – Татарстан Республикасы Милли банкына һәм «Россия Саклык банкы» гавами акционерлар җәмгыятенең «Татарстан Банкы» 8610 нчы бүлегенә сайлау компанияләре чорында Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, башка сайлау комиссияләре соравы буенча тиешле сайлау комиссияләре каршындагы тикшерү-ревизия хезмәте составында эшләү өчен белгечләрне командировкага җибәрүне тәкъдим итәргә.

18. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә, үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

сайлау комиссияләренә кирәкле урыннар (беренче каттан да югарырак урнашмаган тавыш бирү урынын, сайлау документларын саклау урынын һәм булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә сайлаучыларны кертү турындагы гаризаларны кабул итү урынын да кертеп (шул исәптән бу урыннарны һәм сайлау документларын саклауны тәэмин итәргә), транспорт чараларын, элемтә чараларын һәм техник җайланманы (шул исәптән участок сайлау комиссияләренең машина укый ала торган кодлы тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрен эшләү технологиясен куллану өчен) түләүсез нигездә (урыннарны файдаланган өчен чыгымнарны капламыйча һәм аларга түләмичә, коммуналь хезмәтләрне түләү өчен) бирүне һәм аларны саклауны тәэмин итүне, шулай ук, кирәк булганда, сайлау комиссияләре тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләрнең үтәлүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка булышлык күрсәтүне;

булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә сайлаучыларны кертү турында гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениеесе белән килешүгә кул куюны тәэмин итүне;

сайлаучылар исемлекләрен төзү һәм ачыклау өчен сайлаучылар турындагы мәгълүматларны территориаль сайлау комиссияләренә кертүне;

сайлаулар үткәрүне оештыручы сайлау комиссияләре тәкъдимнәре буенча һәр сайлау участогы территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бирүне;

сайлау участокларын оештыруга һәм сайлау комиссияләрен формалаштыруга бәйле булган, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү барышы, сайлау гамәлләрен кылу

вакытлары һәм тәртибе, кандидатлар һәм сайлау берләшмәләре турында сайлау комиссияләре кертә торган мәгълүматны бастырып чыгаруны тәэмин итүне;

«Сайлаулар» Россия Федерациясе автоматлаштырылган дәүләт системасының өзлексез эшләве өчен кирәкле норматив технологик шартларны тәэмин итүне;

тавыш бирү урыннарын инвалидларга, халыкның аз хәрәкәтләнә торган башка төркемнәренә үзләренең сайлау хокукларын тулысы белән тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган махсус җайланмалар белән җиһазландыруны тәэмин итүне;

сайлаучыларның тавыш бирү урыннарына барып җитү максаты белән җәмәгать транспортының оптималь эшләвен тәэмин итүне;

сайлау комиссияләре сайлау документларын әзерләү эшләрен һәм хезмәтләрен тиешле бюджетлар акчасы исәбеннән финансланучы оешмалар өчен билгеләнгән тарифлар (бәяләр) буенча сатып алуларны гамәлгә ашырганда, аларга булышлык күрсәтүне;

Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе белән берлектә, гамәлдәге урыннарда сайлау комиссияләре эшли алмаган очракларда сайлауларны үткәрү барышы туктаусыз булуны оештыру максатларында, тавыш бирү өчен резерв пунктлар булдыруны күздә тотуны, шулай ук барлык тавыш бирү урыннарында, шул исәптән транспорт инфраструктурасы объектларында, тавыш бирү көнендә стационар металл детекторлар һәм объектив тикшерүдә тотуның техник чаралары белән җиһазландыру чараларын тормышка ашыру мәсьәләсен карауны;

сайлауларны әзерләүдә һәм аларны әзерләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә булышлык күрсәтү буенча эшче төркемнәр төзүне.

19. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2014 ел, 1 август, 561 нче;

«Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2015 ел, 20 июнь, 447 нче;

«Җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2016 ел, 3 май, 277 нче;

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкаләтле органнары депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 август, 620 нче.

20. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны үткәрүдә
сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү һәм аларны үткәрүгә бәйле
мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркем
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, эшче төркем җитәкчесе |
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Вафин Гадел Юныс улы | Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасының финанс министры |
| Гәрәев Раил Рүзәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Житәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Демидов Виктор Николаевич | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасының юстиция министры |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасының икътисад министры |
| Җәббаров Азат Галимҗан улы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш дәүләт теркәүчесе (килешү буенча) |
| Идиатуллин Артур Ревов улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Ильясов Радик Мөдәррис улы | Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кулагин Кирилл Денисович | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан югары танк команда Кызыл Байрак училищесы башлыгы (килешү буенча) |
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Погодин Сергей Николаевич | Татарстан Республикасының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сафиуллин Марат Әдип улы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сөнгатуллин Марат Бәһрам улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры |
| Хәйруллин Эдуард Фәрид улы | Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хәмитов Динар Газиз улы | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хиалиев Эдуард Данил улы | Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Хохорин Артём Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шәвәлиева Альбина Рафаил кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданнар хәле актларын язу идарәсе башлыгы |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |

| | |
|---|---|
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Шәрифуллин Марат Дамир улы | Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе башлыгы урынбасары вазыйфаларын башкаручы – Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлеге – Татарстан Республикасы Милли банкы идарәчесе (килешү буенча). |
| Шәфигуллин Айрат Радин улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы секретаре (килешү буенча). |

_______________________________